Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы торак пунктында узган

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

29 ноябрь, 2021 ел №2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы торак пунктында узган гражданнар җыены КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово, Шетнев-Чирмешән, Зюзино, Наумово авыл торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Корноухово, Зюзино, Шетнев-Чирмешән авылларында урам юлларын кышкы чорда карап тоту (тору) – кардан арындыру;
- Корноухово авылында ЭЦВ 6-10-80 маркалы 1 данә тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру;
- юл-төзелеш материаллары сатып алу һәм Корноухово авылында Яр буе урамының 400м озынлыктагы юл кишәрлеген ремонтлау;
- юл-төзелеш материаллары сатып алу һәм Корноухово авылында Яшел урамының 300м озынлыктагы юл кишәрлеген ремонтлау;
- Корноухово авылында Совхоз, Эшчеләр поселогы урамнарында вак таш түшәлгән юл кишәрлекләрендәге чокырларны ремонтлау эшләре;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авыллары урамнарында юл читләрендәге чүп үләннәрен чаптыру;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авылларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, алыштыру һәм карап тору;
- Корноухово авылында су үткәрү челтәрләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, запас частьләр сатып алу, шартнамә нигезендә хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Корноухово авылында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга куелган стеланы ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Шетнев-Чирмешән авылы, Совет урамы, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзәк урам, 6а йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм шулай ук http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Г.С Гумашян

Корноухово авыл җирлеге Башлыгы: Г.С Гумашян